| СОВЕТ БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БУТЛЕРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.05.2020 с. Мокрые Курнали № 135

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Бутлеровка авыл җирлегендә
Бюджет корылышы һәм бюджет
процессы турындагы нигезләмәнең
аерым пунктларының гамәлдә
булуын туктатып тору турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 01 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

Бутлеровка авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге карары белән расланган Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәнең 2015 елның 26 гыйнварындагы 107а номерлы (вакытлар өлешендә) 32 маддәсендәге 3 пунктының 1 абзацының, 2 пунктының, 18 маддәнең 3 пунктының, 2 пунктының гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Алексеевск муниципаль районының
Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Ф.А.Хайрутдинова